| Республика Татарстан<br>Совет Старомензелябашского<br>сельского поселения<br>Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районы<br>Иске Минзәләбаш авыл җирлеге<br>Советы |
|---|---|

РЕШЕНИЕ — КАРАР

2024 ел 23 ноябрь — № 21

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 30 сентябрендәге 338-ФЗ номерлы Федераль законның 1 абзацы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 08.08.2024 N 232-ФЗ номерлы Федераль закон, Сарман муниципаль районының «Иске Минзәләбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең 2022 елның 14 февралендәге 4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Минзәләбаш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6.3. Җирле үзидарә органы җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, мәнфәгатьләр конфликтын төшереп калдыру максатларында җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары әлеге органның сайланулы профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен алар тарафыннан тиешле вазыйфаны биләү чорында тапшыра алмый.»;
2) 9.3 пунктның 5 пунктчасында «һәм квалификация турында»сүзләрен өстәргә.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Советы рәисе — А.Н.Габдрахманов